**Татарстан Республикасы Азнакай районы Советы**
**КАРАРЫ**

Азнакай шәһәре №341-45 «28» май 2025 ел

Татарстан Республикасы Азнакай район Советының 2018 елның 22 августындагы 202-30 номерлы «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасы» муниципаль казна учреждениесе турындагы Нигезләмә хакында» карары белән расланган «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасы» Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясе Җир кодексының 11.10 һәм 39.15 статьяларына һәм «Геодезия, картография һәм пространство мәгълүматлары турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» Федераль законның 18.1 статьясына, «Россия Федерациясе Җир кодексының «Бердәм цифрлы мәгълүмат системасы» федераль дәүләт географик системасы турында» 2022 елның 07 июнендәге 1040 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары нигезендә,

Татарстан Республикасы Азнакай районы Советы карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Азнакай район Советының 2018 елның 22 августындагы 202-30 номерлы «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасы» муниципаль казна учреждениесе турындагы Нигезләмә хакында» карары белән расланган «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасы» Нигезләмәгә (14.12.2023 №256-29 карар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. «Палата вазифалары» 3 бүлегенә түбәндәге эчтәлекле 3.35 пунктчаны өстәргә:

«3.35. Палата үз вәкаләтләрен тәэмин итү өчен дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен билгеләнгән автоматлаштырылган мәгълүмат системаларын, шулай ук киңлек мәгълүматларының милли системасы эшчәнлеген тәэмин итә торган федераль дәүләт географик мәгълүмат системасын куллана.»

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча» урнаштырырга: http://aznakaevo.tatar.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис М.З. Шәйдуллин